**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ КАРАБАШ БИСТӘСЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**ИЛЛЕ СИГЕЗЕНЧЕ СЕССИЯ**

**КАРАР № 2**

Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе «20» май 2019 ел

**«Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турында» Нигезләмәне раслау хакында» Бөгелмә муниципаль районы «Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 3 июлендә булып узган XXVI сессиясендә кабул иткән 1нче карарына үзгәрешләр кертү турында яңа басмада**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән №131-ФЗ Федераль законга туры китерү максатларында һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп,

**«Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе»**
**муниципаль берәмлеге Советы**

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 3 июлендә булып узган XXVI сессиясендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турында»гы Нигезләмәне раслау хакында»гы 1нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлектә:

*- 1 бүлекнең 22 пунктын яңа басмада бәян итәргә:*

«22) Бөгелмә муниципаль районының «Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе» муниципаль берәмлегенең генераль планын, җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре раслау, «Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе» муниципаль берәмлегенең генераль планы нигезендә территорияне планлаштыру буенча әзерләнгән документларны, төзелешкә рөхсәт бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда

каралган очраклардан тыш), Бөгелмә муниципаль районының «Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә төзелешне тормышка ашырганда объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү, Бөгелмә муниципаль районының «Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе» муниципаль берәмлегендә шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларны раслау, муниципаль ихтыяҗлар өчен Бөгелмә муниципаль районының «Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе» муниципаль берәмлеге чикләрендәге җирләрне резервлау һәм җир кишәрлекләрен алу, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе» муниципаль берәмлеге чикләрендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда, тикшерү үткәрү, мондый тикшерүләр барышында ачыкланган закон бозуларны бетерү буенча тәкъдимнәр бирү, шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамә җибәрү (алга таба - планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамә) шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларын билгеләнгән параметрларга һәм индивидуаль торак төзелеше объекты яисә җир кишәрлегендә бакча йорты урнаштыруның рөхсәт ителгән булуына һәм рөхсәт ителгән параметрларга туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү (алга таба - планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә), индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамә бирү, Бөгелмә муниципаль районының «Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортларын төзегәндә яки реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килү я килмәү турында хәбәрнамә бирү, Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә үзирекле корылмаларны сүтү турында карар кабул итү, үзбелдек белән төзелгән корылмаларны сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары белән тәңгәлләштерү турында карар бирү, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, территорияне планлаштыру буенча документлар яки федераль законнар белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр (алга таба - билгеләнгән таләпләргә туры китерү) билгеләү, максатчан кулланылучы җир участогын яки Россия Федерациясе законнарын бозып кулланылучы җир участокларын алу турында карар кабул итү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда, үзбелдек белән төзелгән бинаны сүтүне яисә аны тиешле таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыру;».

1.2 4 бүлектә:

*- 2 пунктның 5 абзацын яңа басмада бәян итәргә:*

«- «Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе» муниципаль берәмлеге ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр, хезмәтләр, товарлар сатып алуны гамәлгә ашыра;»;

1.3 5 бүлектә:

*- 12 пунктны түбәндәге басамада бәян итәргә:*

«12) «Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннарга мөнәсәбәттә эшчәнлекне гамәлгә ашыру;».

- *түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:*

«15) «Куллланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә басылып чыканнан соң, үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**«Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **М.Т.Минхәйдәров**